СОВЕТ ПИЖМАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЫЖМАРА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«29» ноябрь 2024 ел № 112

**2022 елның 29 июнендә кабул ителгән 49 номерлы «Милеккә салым турында» гы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү хакында (27.09.2024ел 104 нче номерлы үзгәрешләре белән)**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Пыжмара авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Милеккә салым турында» 2022 елның 29 июнендәге 49 номерлы Пыжмара авыл җирлеге советы карарына (27.09.2024ел 104 нче номерлы үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 2.4 пунктта «, шулай ук һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.».

2. Әлеге карарны рәсми рәвештә Татарстан Республикасының pravo.tatarstan.ru хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Пыжмара авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан мизгел нигезендә үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тәэсир итә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Пыжмара авыл җирлеге башлыгы өстенә йөкләргә.

Пыжмара авыл
җирлеге башлыгы Р.Х. Заляев